# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Саурыш авыл җирлеге составына керүче Түбән Сауруш торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында.

2019 елның 27 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлегендә Түбән Сауруш пунктында(авыл) халык җыены карар итте:

1. 2020 елда Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге Түбән Сауруш торак пункты (авыл) территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

**1.Авыл җирлеге чикләрендә, шул исәптән җирлек чикләрендә җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

1). Түбән Сауруш торак пунктында (авылында) вак таш җәелгән юлларны ремонтлау.

2).Түбән Сауруш авылы урамнарын карап тоту.

3). Түбән Сауруш авылында буаны ремонтлау.

**2.Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп).**

1). Түбән Сауруш авылында урамнарны яктырту өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Саурыш авыл җирлеге башлыгы: А. Г. Кузьмин